# ИЛГИЗӘР СОЛТАН



**Шайхутдинова Алия Ильмировна ,**
**учитель татарского языка и литературы**
**МБОУ Базарно – Матакская гимназия имени Наби Даули Алькеевского муниципального района РТ**

Илгизәр Солтан улы Гыйбадуллин 1961 нче елның 29 нчы гыйнварында Әлки районы Иске Әнҗерә авылында туа.Сигезьеллык белемне туган авылы мәктәбендә ала. Мәктәпне 1976 нчы елда тәмамлый.

6 балалы ишле гаиләдә олы ир бала булганга, бәләкәйдән үк өй тирәсендәге эшкә катнашып ир – ат һөнәренә өйрәнеп үсә. Җәйге каникул вакытында әтисе белән машинада иген ташый, комбайнчы ярдәмчесе булып эшли.

1976-1980 нче елларда Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумында укый.

Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, укыган белеме буенча авыл хуҗалыгында агроном булып эшли.

Аннан соң белемен арттыру өчен Казан авыл ху-җалыгы институтына укырга керә.1989 елда аны тәмамлый.

КСХИ да укыганда “Татарстан яшьләре”газета-сы каршындагы “Яшьлек”әдәби берләшмәсендә бер төркем язучылар тарафыннан шигырьләре карала һәм матбугатта бастырып чыгарырга тәкъдим ителә.

1989- 1994нче елларда Питрәч районының “Искра”колхозында баш агроном булып эшли

Мәктәптә укыганда ук каләм тибрәткән Илги-
зәрнең беренче шигырьләре 1973 нче елда
“ Яшь ленинчы”, “Коммунизм юлы”газетала-
рында “Шигърият почмагында ”басылып чыга.



1991 нче елда Илгизәр Солтан Татарстан Язучылар Союзына тәкъдим ителә.Шул ук елда кече яшьтәге балалар өчен “Карлар таган атына” исемле беренче китабы басыла.

1992 нче елда “Бер тауда уң чишмә”дигән күмәк җыентыкта,1993 нче елда “Туган якта кунакта ” китаплары дөнья күрә.

2000нче елда Казанга күченә һәм Язучылар Союзы берлеге әгъзасы булып санала.

2002 нче елда “Тәмле телле малай”исемле китабы басыла.

# Илгизәр Солтанның басылып чыккан китаплары












# ИЛГИЗӘР СОЛТАННЫҢ ТУГАН ЙОРТЫ



Зур иҗат эшенә җиң сызганып тотынгач кына, күпме язылган шигырьләрен,алдагы зур план-нарынтормышка ашыра алмыйча,ул безнең арабыздан мәңгелеккә китте.

Тормышның фаҗигале язмышы 2005 нче елда Илгизәрнең гомерен өзде, ләкин аның белән булган очрашулар,әдәби кичәләр безнең күңелебездә мәңге сакланыр, ә шигырьләренә язылган көйләр  безне озата барырлар.

## Илгизәр Солтан сүзләренә язылган җырлар:
## 1.Миләүшәләр



# Яңа ел

Марат Мухин көе
Илгизәр Солтан сүзләре

Күңелемдә — яңа уйлар,
Биеп йөри хыял.
Алла бирсә, барысы да
Чынга ашар быел…
Яңа елны, яңа көнне,
Көтеп алдык, көтеп.
Яңа көнгә керик дуслар,
Бисмилланы әйтеп…
Алла бирсә, алла бирсә,
Чынга ашар хыял.
Үткән елдан бәхетлерәк
Булырбыз без быел…
Яңа елны, яңа көнне,
Көтеп алдык, көтеп.
Яңа көнгә керик дуслар,
Бисмилланы әйтеп…
Күңелемдә — якты уйлар,
Күзләремдә — нурлар.
Бер — берсеннән аермасын
Иркәм, безнең куллар.

DOTA.RU - лучшие обои

## Безнең авыл

Безнең авыл бик матур –
Урман якын булганга.
Су буендагы талларга,
Сандугачлар кунганга.
Безнең урам бик матур
Өйләр якты булганга.
Һәр көн саен тәрәзләргә
Кояш нуры кунганга.
Безнең өй дә бик матур
Матур ул мин булганга.
Ә мин нигә соң матур?
Матур җирдә туганга.
Тәрәзәне ачып куям
Мин елмаеп торам да.
Йөгереп чыгам урамга
Матур җирдә уйнарга.



Илгизәр Солтанның бертуган сеңлесе
искә алу кичәсендә
(беренче рәттә уңнан дүртенче)

# Источник:


1. 1. 1. ://katyaburg.ru/razdely/kr…
2.2. 2. http://kurai.at.ua/blog/chego_…
3. http://muzofon.com/